ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ДРОЖЖАНОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧҮПРӘЛЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

19.04.2021 с.Старое Дрожжаное №147

Торак урыны мәйданының исәп нормасы һәм социаль найм шартнамәсе буенча торак урыны мәйданын бирү нормасы турында

Россия Федерациясе Торак кодексының 50, 58 статьяларын гамәлгә ашыру, дәүләт торак программаларын гамәлгә ашыру максатларында, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Уставының 44 статьясына таянып, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районында торак урын мәйданының исәпкә алу нормасын билгеләргә, шуннан чыгып, гражданнарны торак урыннарга мохтаҗлар буларак исәпкә алу максатларында аларның торак урынының гомуми мәйданының гаиләнең бер әгъзасына 12 кв. метрдан артмаган күләмендә торак урын белән тәэмин ителеш дәрәҗәсе билгеләнә.

2. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районында, социаль найм шартнамәләре буенча бирелә торган торак урыннар белән тәэмин ителешнең ирешелгән дәрәҗәсеннән чыгып, бер гражданга торак урынның гомуми мәйданының 18 кв. метр күләмендә торак урын бирү нормасын билгеләргә.

3. Торак урынының гомуми мәйданын бирү нормасын арттыру Россия Федерациясе Торак кодексында каралган очракларда рөхсәт ителә.

4. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы буенча гражданнарга социаль найм һәм Дәүләт торак программалары буенча торак бирү һәм исәпкә куелганда торак мәйданы нормалары турында» 2006 елның 26 июлендәге 258 номерлы карары үз көчен югалткан дип танырга.

5. Әлеге карар Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районынын рәсми сайтында урнаштырылырга һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча басылып чыгарга тиеш: http://pravo.tatarstan.ru

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктур үсеш буенча урынбасары И.С. Бикчуровка йөкләргә.

Башкарма комитет